ГЛАВА СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская, д.12, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Иске Каразирек авылы, Совет урамы, 12 йорт, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 1** **30 ноябрь 2021 ел**

2022 елда Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегендәге Яңа Каразирек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 9 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Пионерлар урамы, 18 йорт, авыл клубы бинасы янында.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Яңа Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Яңа Каразирек авылы, Пионерлар урамына асфальт юл җәю.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Иске Каразирек авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

“Иске Каразирек авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Вәлиев